РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

______________　　с. Куралово　　______________

58　　　　　　　　　　20.08.2016

Куралово авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт мөлкәти хезмәт күрсәтүләр исемлеген раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген расларга (1-нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Башкарма комитетының «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2013 елның 21 маендагы 32 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Куралово авыл җирлеге Башкарма комитет җитәкчесе　　Н.Н. Шипшова

Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2016 елның 20 августында
№ 58 карарына
1 номерлы кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге башкарма комитеты күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре исемлеге

№
т/б
Дәүләт хезмәтенең аталышы

1. Тууны дәүләт теркәве.
2. Никахлашуны дәүләт теркәвенә алу.
3. Никахны өзүне дәүләт теркәве.
4. Ата булуны билгеләүне дәүләт теркәве.
5. Үлемне дәүләт теркәве.

Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге башкарма комитеты күрсәтә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге

№
т/б
Муниципаль хезмәт атамасы

1. Күчемсез милек объектын бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару.
2. Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль милектәге торак урынны бирү.
3. Кадастр исәбенә кую максатында муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренең чикләрен килештерү.
4. Җир кишәрлегенә белешмә, йорт биләмәсенә белешмә, гаилә составы турында белешмә, яшәү урыныннан белешмә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтә бирү.
5. Документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген таныклау
6. Җир кишәрлеген сайлау актын килештерү.
7. Гражданнар милкенә торак урыннарны тапшырганда документларны рәсмиләштерү
8. Җирлекнең генераль планыннан өземтә бирү